ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

09.08.2019 ел Баулы шәһәре №229

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
2019 елның 11 мартында кабул
ителгән карары белән расланган
«2019-2023 елларда Татарстан
Республикасы Баулы муниципаль
районында кече һәм урта эшкуарлыкны
үстерү» муниципаль программасына
үзгәрешләр һәм естәмәләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 179 статьясы 2нче бүлеге, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән 131нче номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 11 мартында кабул ителгән карары белән расланган «2019-2023 елларда Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләр һәм естәмәләрне кертергә:

программаның «муниципаль программа паспорты» дигән бүлегендә «Финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» юлында 2нче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Программаны гамәлгә ашыру өчен финанс чараларына гомуми ихтыяҗ 7 млн.400 мең сум тәшкил итә (җирле бюджет, республика бюджеты акчалары). Искәрмә: программаны финанслау күләме фаразлы булып тора һәм тиешле дәрәҗәдәге бюджетлар формалаштыруны исәпкә алып, тиешле елга һәм план чорына ел саен тезәтмәләр кертелергә тиеш»;

программага 2нче «2019-2023 елларда Баулы муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль программасының теп чаралары исемлеге» кушымтасында «КУЭ субъектларына финанс ярдәм чараларын гамәлгә ашыру» 3 пунктында 1 пунктчада 5 баганада «җирле бюджет 7 млн. 400 мең сум» сүзләрен һәм саннарын өстәргә.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисади үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров